Татарстан Дәүләт Советы
Рәисе Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшинга
Апас районы Янгелде авылында яшәүче
Җәләлова Рузалия Абзаловнадан

Хөрмәтле Фәрит Хәйруллович! Исәнмесез. Мөмкин булса, Сезнең аша врачларга рәхмәт җиткерергә иде исәбем.

Январь аенда егылып, аркамны бик авырттырдым. Егылган килеш, ике атна дару ашап өйдә тордым. Чыдар әмәл калмагач Апас район хастаханәсенә мөрәҗәгать иттем. Рәхмәт яусын врачларга, иң беренче чиратта Хирургия бүлеге җитәкчесе Әхмәтҗанов Нияз Назыйровичка. Тиешле снимокларны ясап, диагнозны ачыклады – умырткамда компрессион перелом барлыгын ачыклады. Хастаханәдә ятып калырга туры килде.

Менә шул дәвердә бу врачларның эш режимын күреп яттым инде. Алла ярдәм генә бирсен аларга. Көн-төн катлаулы операцияләр, ял көне дип тору юк, Нияз Назыйрович көн дә хастаханәдә. Рөстәм Үзбәкович Гайнуллин да тәүлек буе авырулар янында. Бик катлаулы хезмәтләре, ай-хай.

Арыдым дип тору юк, операцияләрдән соң да һәр кон берничә тапкыр да кереп чыгалар палаталарга, бик игътибарлы врачлар. Безнең кебек картларга да игътибарны кызганмыйлар, кызлар да билгеләнгән уколларны, дәваларны да вакытында ясыйлар.

Эшне шулай төгәл оештырган өчен баш табиб Алмаз Альфредовичка зур рәхмәт. Яшь булса да, тәҗрибәле икән.

Фәрит Хәйруллович, палатада бергәләп яткан ханымнар рәхмәтен дә җиткерәсе килгән иде врачларга. Минем исемнән генә түгел бу. Депутатларыбыз да белеп торсын дип зуым, дөресрәге, оныгыма әйтеп торып яздырам менә.

Алланың рәхмәтләре яусын аларга. Дәваларның ярдәме белән безгә дә сырхаусыз гына яшәргә булсын.

Олы хөрмәт белән Рузалия Җәләлова, 74 яшендә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ
ГОСУДАРСТВЕННОГО
СОВЕТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
«04» 02 2020 г.
№ 3-458